**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Баграж авыл җирлеге Советы**

# К А Р А Р

**№ 140** **10.12.2024 ел**

**“Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында” 2018 елның 23 апрелендәге 106 номерлы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2018 елның 23 апрелендәге 106 номерлы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге Советының “Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында” карарына (Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге Советының 21.05.2018 № 108, 07.12.2018 № 137, 24.09.2020 № 7, 30.12.2021 № 40, 30.09.2022 № 62, 30.11.2022 № 65, 15.03.2023 № 85, 25.06.2024 № 125 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә:

2.2 пунктта «13 323 сум» сүзен «13 990 сум» сүзе белән алыштырырга;

2.14 пунктта «13 323 сум» сүзен «13 990 сум» сүзе белән алыштырырга;

1.2. Әлеге карар белән расланган “Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында” нигезләмәгә 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Баграж авыл җирлеге башлыгына акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19 173 |

2. Карарны Баграж авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Билгеләү:

әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә;

әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә әлеге Нигезләмәгә локаль актларны туры китерергә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет Рәисе, Баграж**
**авыл җирлеге башлыгы** **П.Н. Минеев**